ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь, 2015 ел № 4/8

2016 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) раслау турында

2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ санлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2016 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) кушымтадагыча расларга.
2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
4/8 нче Карарына
кушымта
17 декабрь, 2015 ел

**2016 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру фараз планы (программасы)**

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2016 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру фараз планы (программасы) (алга таба – Фараз планы) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ санлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә туры китереп эшләнгән.
2. 2016 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлтелгән.
3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә туры китереп, муниципаль милекне законда каралган ысуллар белән хосусыйлаштыру күздә тотыла.

2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2016 елда муниципаль казнада торучы һәм муниципаль предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә файдаланууда булмаган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.
5. Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендге 33/9 санлы Карары (Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/12, 2015 елның 22 октябрендәге 32/15 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган 2015 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милеген хосусыйлаштыру фараз планына (программасына) кертелгән, хосусыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш, хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенең 6, 7 пунктларыннан тыш.
6. 2016 елда муниципаль унитар предприятиеләрне һәм муниципаль милектә булган акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.
7. Күчемсез милекне хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру шартлары турында, шул исәптән тартып алу белән бер үк вакытта затка сатылган милекне һәм әлеге милек биләгән һәм аннан файдалану өчен зарури булган җир кишәрлеген хосусыйлаштыру шартлары турында карар Шәһәр Советы карарлары нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

8. Фараз планы гамәлдә булу дәвамында 2016 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенә Шәһәр Советы карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3 бүлек. Яр Чаллы шәһәре милеген хосусыйлаштыруның мәгълүмати тәэмин ителеше

9. Яр Чаллы шәһәре милеген хосусыйлаштыру турында мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм рекламаны тагын да киңрәк күрсәтү максатында, Башкарма комитет әлеге Фараз планының үтәлеше барышында федераль законда каралган тәртиптә гаммәви мәгълүмат чаралары хезмәтеннән файдаланырга хокуклы.